МИНИСТЕРСТВО КУЛЬТУРЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӘДӘНИЯТ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

23.10.2017 г. Казань № 920 од

2014 елның 20 гыйнварында Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының 22 од номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү турында Нигезләмәгә үзгәреш кертү турында

"Россия Федерациясенең дәүләти гражданлык хезмәте турында" 2004 елның 27 июле № 79-ФЗ Федераль законы, "Россия Федерациясе дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында" 2005 елның 1 феврале № 112 Россия Федерациясе Президенты Указы, "Татарстан Республикасында дәүләти гражданлык хезмәте турында" 2003 елның 16 гыйнвары №3-ТРЗ Татарстан Республикасы законы, "Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтендә кадрлар резервы турындагы Нигезләмәне раслау турындагы" 2011 елның 14 марты № УП-127 Татарстан Республикасы Президенты Указы, "Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарга тест уздыруны оештыру мәсьәләләре" турында 2015 елныд 11 декабре № УП-1192 Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә

БОЕРАМ:

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының 2014 елның 20 гыйнвары 22 од номерлы "Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү турында Нигезләмә турындагы" (Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының 19.06.2014 ел, № 679 од, 24.10.2016 ел, № 916 од боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү турында Нигезләмәгә үзгәреш кертеп, аны яңа редакциядә бирергә

**Министр** **А.М.Сибагатуллин**

Татарстан Республикасы
Мәдәният министрлыгы
Боерыгы
(Татарстан Республикасы
Мәдәният министрлыгының
23.10.2017ел, № 920 од
боерыгы редакциясендә)
нигезендә расланган

**Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турында Нигезләмә**

## 1.Гомуми нигезләмәләр

1.1.Бу Нигезләмәдә Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү буенча Конкурс комиссиясе (алга таба – конкурс комиссиясе) составы, эш сроклары һәм тәртибе, шулай ук Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгында (алга таба – Министрлык) Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү методикасы билгеләнә.

Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс (алга таба - конкурс) Россия Федерациясе гражданнарының Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтенә (алга таба – гражданлык хезмәте) бертигез дәрәҗәдә керү мөмкинлегенә Россия Федерациясе гражданнарының конституцион хокукын, шулай ук, дәүләти гражданлык хезмәткәрләренең (алга таба – гражданлык хезмәткәрләре) конкурс нигезендә вазыйфаи үсешкә хокукын билгели.

1.2. Конкурс Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгында (алга таба – Министрлык), “Россия Федерациясендә дәүләти гражданлык хезмәте турында” 27 июль, 2004 ел, №79-ФЗ Федераль законның 22 маддәсе (алга таба – Федераль закон), “Россия Федерациясе дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында” 2005 елның 1 феврале № 112 Россия Федерациясе Президенты Указы, “Татарстан Республикасында дәүләти гражданлык хезмәте турында” 2003 елның 16 гыйнвары №3-ТРЗ Татарстан Республикасы законы, “Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтендә кадрлар резервы турындагы Нигезләмәне раслау турындагы” 2011 елның 14 марты № УП-127 Татарстан Республикасы Президенты Указы, “Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарга тест уздыруны оештыру

мәсьәләләре” турында 2015 елныд 11 декабре № УП-1192 Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә үткәрелә.

Конкурс дәгъвачыларның Министрлыкта гражданлык хезмәтенең (алга таба – гражданлык хезмәте) вакантлы вазыйфасын биләүгә һөнәри дәрәҗәсен бәяләүдән, аларның әлеге вазыйфага карата билгеләнгән квалификацион таләпләренә туры килү-килмәвен бәяләүдән гыйбарәт.

1.3. Министрлыкта вакантлы вазыйфаны биләүгә конкурс Федераль закон нигезендә конкурс үткәрелергә мөмкин булган гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасы булганда Татарстан Республикасы мәдәният министры (аның вазыйфаларын башкаручы зат) (алга таба – министр) карары нигезендә игълан ителә.

1.4. Министрлыкның кадрлар резервына кертүгә конкурс кадрлар бүлеге тарафыннан Министрлыкның гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү өчен белгечләргә ихтыяҗына һәм Министрлыкта булган кадрлар резервына ел саен бәяләү үткәрү нәтиҗәсендә оештырыла.

Министрлыкның кадрлар резервына кертүгә конкурс Министрлыкның конкурс комиссиясе тарафыннан әлеге Нигезләмәдә каралган тәртиптә үткәрелә.

1.5. Министрлыкта вакантлы вазыйфаны биләүгә конкурс үткәрелми:

“җитәкчеләр” һәм “ярдәмчеләр (киңәшчеләр)” категорияләрендә дәүләт хезмәте вазыйфасы вәкаләтләренә билгеле бер срокка билгеләгәндә;

сроклы хезмәт контракты төзегәндә;

гражданлык хезмәткәрен гражданлык хезмәтенең башка вазыйфасына Федераль законның 28 маддәсенең 2 өлешендә, 31 маддәсенең 1 өлешендә һәм 60.1 маддәсенең 9 өлешендә күздә тотылган очракларда билгеләгәндә;

гражданлык хезмәте вазыйфасына гражданлык хезмәтендә кадрлар резервына кертелгән гражданлык хезмәткәрен (гражданны) билгеләгәндә.

1.6. Министрлыкта вакантлы вазыйфаны биләүгә конкурс үткәрелми үткәрелмәскә мөмкин:

вазыйфа бурычларын үтәү Министр боерыгы белән расланган вазыйфалар исемлеге нигезендә дәүләт сере булып торган мәгълүматлардан файдалану белән бәйле булган гражданлык хезмәтенең аерым вазыйфаларына билгеләгәндә;

министр карары буенча гражданлык хезмәтенең кече вазыйфалары төркеменә керүче гражданлык хезмәте вазыйфаларына билгеләгәндә.

1.7. Конкурс түбәндәге максатларда үткәрелә:

сәләте һәм һөнәри әзерлеге нигезендә Россия Федерациясе гражданнарының гражданлык хезмәтенә бертигез дәрәҗәдә керү мөмкинлегенә хокукларын тәэмин итү, шулай ук гражданлык хезмәткәрләренең конкурс нигезендә вазыйфаи үсешкә хокукларын тәэмин итү;

Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасынынң башка норматив хокукый актларында билгеләнгән таләпләргә туры килүче һәм конкурста катнашуга кертелүче кандидатның гомуми саныннан гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү өчен иң кулай кандидатларны сайлап алу;

Министрлыкның гражданлык хезмәте вазыйфаларына кадрлар резервын формалаштыру.

1.8. Конкурслар үткәрүдә хәл ителә торган бурычлар:
конкурс биремнәрен һәм процедураларын үтәүдә барлык кандидатларга тигез шартлар тәэмин итү;

кандидатларны объектив һөнәри әһәмиятле критерийлар нигезендә бәяләү;
конкурс процедуралары барышында конкурста катнашучылар арасыннан объектив һәм нигезле күрсәткечләрне чагыштыру юлы белән гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфалары таләпләренә туры килүче (кадрлар резервына кирәрлек) затларны билгеләү.

## II. Конкурс комиссиясен формалаштыру һәм эш тәртибе

2.1. Конкурс үткәрү өчен Министрлыкта министр боерыгы белән даими нигездә эшләүче конкурс комиссиясе оештырыла. конкурс комиссиясе составы министр боерыгы белән раслана. Комиссия составына кергән вазыйфалы затларның шәхси составы үзгәргән очракта министр боерыгы белән тиешле үзгәрешләр кертелә.

2.2. Конкурс комиссиясе комиссия рәисеннән, рәисе урынбасарыннан, секретаре һәм әгъзаларыннан тора.

2.3. Комиссия рәисе конкурс комиссиясе эшчәнлегенә җитәкчелек итә. Комиссия рәисе булмаган очракта аның хокукларын һәм бурычларын конкурс комиссиясерәисе урынбасары башкара.
Конкурс комиссиясе секретаре комиссия эшен тәэмин итә (гаризаларны теркәү, делолар булдыру, конкурс комиссиясе карарларын рәсмиләштерү һ.б.).

2.4. Конкурс комиссиясе составына министр һәм (яисә) аның тарафыннан вәкаләтләнгән гражданлык хезмәткәрләре (шул исәптән кадрлар бүлегеннән һәм , хокукый бүлектән) һәм Министрлыкның гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрелә торган структур бүлекчәсеннән, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты вәкиле, Министрлыкның Җәмәгать советы вәкиле, шулай ук министр запросы буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан, гражданлык хезмәте белән бәйле мәсьәләләр буенча белгечләр – бәйсез экспертлар сыйфатында, экспертларның персональ мәгълүматларын күрсәтмичә чакырыла торган фәнни һәм мәгариф учреждениеләр, башка оешмалар вәкилләре керә.
Министрлык карамагындагы Җәмәгать советы вәкилләре һәм бәйсез экспертларның гомуми саны конкурс комиссиясе әгъзаларының гомуми санының кимендә дүрттән берен тәшкил итергә тиеш.

2.5. Вазыйфаи бурычларын үтәү дәүләт сере булып торучы мәгълүматлардан файдалануга бәйле булган гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү өчен конкурс комиссиясе составы дәүләт сере турында Россия Федерациясе канунияте нигезләмәләреннән чыгып булдырыла.

2.6. Конкурс комиссиясе составы конкурс комиссиясе тарафыннан кабул ителә торган карарларга йогынты ясардай мәнфәгатьләр низагы килеп чыкмаслык итеп формалаштырыла.

2.7. Конкурс комиссиясе утырышы гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) кимендә ике кандидат булганда үткәрелә һәм утырышта комиссия әгъзаларының гомуми санынннан кимендә өчтән ике өлеше катнашса хокуклы дип санала. Конкурс комиссиясе утырышын бары тик гражданлык хезмәте вазыйфасын биләүче әгъзалар катнашындагына үткәрү рөхсәт ителми.

2.8. Конкурс комиссиясе карары кандидат югында кабул ителә.

2.9. Конкурс үткәрү нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе карары утырышта катнашкан әгъзаларның күпчелек тавышы белән ачык тавыш бирү нигезендә кабул ителә. Тавышлар бертигез булганда, конкурс комиссиясе рәисенең тавышы хәлиткеч булып тора.

2.10. Конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан кабул ителә торган карарлар (комиссиянең тавыш бирү нәтиҗәләре) конкурс комиссиясе беркетмәсе белән рәсмиләштерелә, комиссия рәисе, рәис урынбасары, секретаре һәм утырышта катнашкан комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана.

2.11. Конкурсны турыдан-туры оештыру һәм аны үткәрүне, конкурс комиссиясенең эшен Министрлыкның кадрлар бүлеге тәэмин итә.

## III. Конкурсларда катнашучылар

3.1. Конкурста катнашуга Министрлыкта гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) дәгъва кылучы кандидатларга куелган таләпләргә туры килүче һәм әлеге Нигезләмәнең 3.4 пунктында күрсәтелгән документларны әлеге Нигезләмәнең 3.7 пунктында билгеләнгән вакыт эчендә тапшырган гражданнар кертелә.

3.2. Граждан (гражданлык хезмәткәре) конкурста катнашуга гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (гражданлык хезмәте кадрлар резервына кертүгә) дәгъва кылу өчен тиешле квалификация таләпләренә туры килмәү белән бәйле рәвештә, шулай ук Федераль законда билгеләнгән чикләүләргә бәйле рәвештә кертелми.

3.3. Минстрлыкның кадрлар резервына Федераль законның 57 маддәсенең беренче өлешенең 2 яисә 3 пунктларында яки 59.1 маддәсенең 2 яисә 3 пунктларында каралган дисциплинар җәзага дучар булган гражданлык хезмәткәре кертелә алмый.

3.4. Министрлыкта дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) дәгъва кылучы кандидатларга карата таләпләр дәүләти гражданлык хезмәте турындагы Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә билгеләнгән.

3.5. Конкурста катнашуга теләк белдергән Россия Федерациясе гражданы Министрлыкка түбәндәгеләрне тапшыра:

шәхси гариза (әлеге Нигезләмәгә Кушымта)

Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган формада кулдан тутырылган һәм имзаланган, фоторәсемле анкета;

паспорт яисә аны алыштыручы документ күчермәсе (документ үзе конкурска килкәч шәхсән күрсәтелә);

тиешле һөнәри белемне, квалификацияне һәм эш стажын раслаучы документлар;

хезмәт кенәгәсенең нотариаль яки эш (хезмәт) урыны буенча кадрлар хезмәте тарафыннан расланган күчермәсе (хезмәт эшчәнлегенә беренче тапкыр керешелгән очраклардан тыш) яки гражданның хезмәт эшчәнлеген раслаучы башка документлар;

һөнәри белем һәм квалификация турында документлар күчермәләре, шулай ук гражданның теләгенә карап, өстәмә һөнәри белем алу нәтиҗәләре буенча бирелгән квалификацияне яисә аның үсешен раслаучы документларның, гыйльми дәрәҗә, гыйльми исем турындагы документларның нотариаль яки эш (хезмәт итү) урыны буенча кадрлар хезмәтендә расланган күчермәләре;

гражданлык хезмәтенә керүгә һәм аны үтүгә комачаулардай авырулар булмау турындагы документ (Россия Сәламәтлек саклау һәм социаль яклау министрлыгының 14.12.2009 ел, № 984 н боерыгы белән расланган 001-ГС/у формасы).

Федераль закон, башка федераль законнар, Россия Федерациясе Президенты һәм Татарстан Республикасы Президенты указлары тарафыннан каралган башка докуменлар.

3.6. Министрлыкта гражданлык хезмәте вазыйфасын биләп, конкурста катнашуга теләк белдергән гражданлык хезмәткәре Министрлык исеменә гариза тапшыра.

Гражданлык хезмәте вазыйфасын башка дәүләт органында биләп, конкурста катнашуга теләк белдергән гражданлык хезмәткәре Министрлыкка Министр исеменә гариза һәм фоторәсем белән Россия Федерациясе хөкүмәте тарафыннан расланган формада кулдан тутырылып, имзаланган һәм үзе дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфасын башкарган дәүләт органының кадрлар хезмәтендә расланган анкета тапшыра.

3.7. Граждан (гражданлык хезмәткәре) дәгъва кылган дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфаларын башкару дәүләт сере булып торган мәгълүматлардан файдалану белән бәйле булган очракта гражданның (гражданлык хезмәткәренең) ризалыгы белән аңа дәүләт серен һәм закон тарафыннан сакланган башка серне тәшкил иткән мәгълүматларны алу рөхсәтен рәсмиләштерү процедурасы үткәрелә.

Граждан тарафыннан министр исеменә бирелгән мәгълүматлар тикшерүгә дучар ителә.

Электрон рәвештә бирелгән мәгълүматлар Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган тәртиптә автоматлаштырылган тикшерүгә дучар ителә.

3.8. Әлеге Нигезләмәнең 3.4. һәм 3.5. пунктларында күрсәтелгән документлар аларны кабул итү турындагы белдерү “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә дәүләт хезмәте өлкәсендәге дәүләти мәгълүмат системасының рәсми сайтында урнаштырылганнан соң 21 көн дәвамында дәүләт органына граждан (гражданлык хезмәткәре) тарафыннан шәхси, почта аша яисә электрон рәвештә

әлеге мәгълүмати системаны Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган тәртиптә файдаланып тапшырыла.
Документларны Электрон рәвештә тапшыру тәртибе Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланa.

Документларны җитди сәбәпләрсез вакытында тапшырмау, тулы күләмендә тапшырмау яки рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшыру гражданнан (гражданлык хезмәткәреннән) аларны кабул итүдән баш тартуга нигез булып тора.

Документларны вакытында тапшырмау, тулы күләмендә тапшырмау яки рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшыруның җитди сәбәпләре булган очракта министр аларны тапшыруның вакытын күчерергә хокуклы.

## IV. Конкурсны үткәрү методикасы

4.1. Конкурс үткәрүдә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килми торган, кандидатларның һөнәри һәм шәхсән сыйфатларын бәяләү ысулларына нигезләнгән конкурс биремнәре һәм процедуралары кулланыла.

4.2. Кандидатларның һөнәри һәм шәхсән сыйфатларын бәяләү критерийлары Министрлыкның гражданлык хезмәте вазыйфаларына карата куела торган квалификация таләпләре нигезендә эшләнгән.
Конкурс үткәрелә торган вазыйфаларның төркеменә һәм категорияләренә бәйле рәвештә конкурста катнашучыларны бәяләү критерийлары үзгәрергә мөмкин

4.3. Кандидатларны чагыштыру һәм сайлап алу аларның конкурс биремнәрен үтәү һәм конкурс процедураларын узу нәтиҗәләре нигезендә хәл ителә.

4.4. Конкурс ике этапта уздырыла.

4.4.1. Беренче этапта Министрлыкның кадрлар бүлеге түбәнләгеләрне оештыра:

Конкурс үткәрү турында гражданлык хезмәтенең (кадрлар резервының гражданлык хезмәте) вакантлы вазыйфасы атамасын, әлеге вазыйфаны биләүгә дәгъва кылучы кандидатларга карата куела торган таләпләр, гражданлык хезмәтен үтү шартлары, кандидатлар тарафыннан гражданлык хезмәтенең (кадрлар резервының гражданлык хезмәте) вакантлы вазыйфасына дәгъва кылу өчен Министрлыкка тапшырылырга тиешле документларны кабул итү урыны һәм вакыты, әлеге документларны кабул итүне төгәлләү вакыты, конкурсны үткәрүнең якынча датасы, аны үткәрү урыны һәм тәртибе чәм башка мәгълүмати материалларны эченә алган мәгълүматны әзерләү һәм Министрлыкның рәсми сайтында һәм “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә дәүләт хезмәте өлкәсендәге дәүләти мәгълүмат системасының рәсми сайтында урнаштыру;

кандидатлар тарафыннан тапшырылган документларны тикшерү;

гражданның (гражданлык хезмәткәренең) квалификация таләпләренә (һөнәри белем дәрәҗәсе, гражданлык хезмәте, башка төр дәүләт хезмәте), стажы яисә белгечлек буенча эш стажы (тәҗрибәсе), әзерлек юнәлеше, вазыйфа бурычларын үтәү өчен кирәкле һөнәри белемнәр һәм осталык) туры килү-килмәвен тикшерү.

4.4.2. Тикшерү барышында федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары нигезендә гражданның гражданлык хезмәтенә керүенә комачаулык тудырырдай хәлләр ачыкланганда, аңа конкурста катнаштырудан баш тарту сәбәпләре турында министрлык тарафыннан язма рәвештә хәбәр ителә. Граждан конкурста катнашу өчен документларны электрон рәвештә юллаган очракта, аңа конкурста катнаштырудан баш тарту сәбәпләре турындагы мәгълүмат электрон формада, дәүләт гражданлык хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасын кулланып, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән юлланыла.

4.4.3. Конкурста катнашуга кертелмәгән вакантлы вазыйфаны биләүгә дәгъва кылучы бу карарга Россия Федерациясе кануннияте нигезендә шикаять белдерүгә хокуклы.

4.4.4. Конкурсның беренче этабын төгәлләү шарты булып Министрлыкта гражданлык хезмәтенең бер вакантлы вазыйфасына (кадрлар резервының гражданлык хезмәте вазыйфасына) билгеләнгән квалификация таләпләренә туры килерлек кимендә ике кандидатның булуы тора, бу кандидатларны алга таба сайлап алу мөмкинлеген тәэмин итә.

Вазыйфага квалификация таләпләренә туры килерлек нандидатлар булмаганда яисә бер генә кандидат булган очракта конкурс үткәрелмәгән булып игълан ителә. Бу очракта бердәндер кандидатка кандидатлар таләп ителгән санда булмау сәбәпле конкурс үткәрелмәү турында язма рәвештә хәбәр ителә.

4.4.5. Конкурсның беренче этабы төгәлләнгәннән соң министр конкурсның икенче этабының датасы (катнашу өчен документларны тапшыруның соңгы көненнән соң 30 көннән дә артык вакыт үткәнче), вакыты һәм урыны турында карар кабул итә. Дәүләт сере һәм закон тарафыннан сакланучы башка серне тәшкил иткән мәгълүматларга рөхсәт рәсмиләштерү очрагында конкурсның икенче этабын үткәрү вакытын министр билгели.

Кадрлар бүлеге конкурсның икенче этабы башланырга күп дигәндә 15 көн кала Министрлыкның рәсми сайтына, "Интернет" челтәрендә дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмати системасының рәсми сайтына конкурсның датасы, урыны һәм вакыты турындагы мәгълүматны, кандидатлар исемлеген урнаштыра, һәм язма рәвештә кандидатларга тиешле мәгълүматны юллый, конкурста катнашу өчен документларны электрон рәвештә юллаган кандидатларга - әлеге мәгълүмат системасын кулланып, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән юллый.

4.4.6. Икенче этапта түбәндегеләр башкарыла:

конкурс комиссиясе тарафыннан кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатлары бәяләнә;

конкурс комиссиясе тарафыннан Министрлыкта гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасына (кадрлар резервына) конкурста җиңүчене билгеләү турында карар кабул ителә;

4.4.7. Вазыйфаларның әлеге төркеме өчен конкурсның икенче этабында кандидатларны бәяләүдә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килмәгән кандидатларның һөнәри һәм шәхсән сыйфатларын бәяләү ысулларына нигезләнгән конкурс биремнәре һәм процедуралар (компьютерда яки бланкта тест сынаулары) кулланылырга мөмкин.

Конкурс үткәрү барышында конкурс комиссиясе кандидатлар тарафыннан тапшырылган белем, гражданлык яисә башка төр дәүләт хезмәте үтү, башка төр хезмәт эшчәнлеге башкару турындагы документлары нигезендә, шулай ук Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килмәгән һөнәри һәм шәхсән сыйфатларын бәяләү ысулларына нигезләнгән тест сынаулары һәм башка төр конкурс процедуралары үткәрү, шул исәптән Министрлыкта кандидатлар дәгъва кылган дәүләт гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасы (дәүләт гражданлык хезмәтенә кадрлар резервы) буенча вазыйфаи бурычларны башкаруга бәйле мәсьәләләр буенча тест сынаулары һәм шәхси әңгәмә үткәрү нигезендә кандидатларны бәяли.

4.8. Министрлыкта дәүләт гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасына (кадрлар резервына кертүгә) дәгъва кылучы кандидатларга тест сынаулары Татарстан Республикасы Президента карамагындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан расланган тестлар үткәрү методикасына нигезләнеп үткәрелә.

4.4.9. Тест сынаулары үткән кандидатлар белән шәхси әңгәмәне конкурс комиссиясе әгъзалары үткәрә.

Киләчәктәге һөнәри хезмәт эшчәнлеге темасы буенча конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан бирелүче сорауларга кандидатларның җавапларыннан гыйбарәт шәхси әңгәмә барышында конкурс комиссиясе дәүләт гражданлык хезмәтенә квалификация таләпләреннән һәм бу вазыйфа буенча регламентның башка кагыйдәләреннән, шулай ук әлеге Нигезләмә һәм дәүләт гражданлык хезмәте турындагы Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы кануните тарафыннан билгеләнгән башка кагыйдәләрдән чыгып кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяли.

4.5. Конкурсның икенче этабы нәтиҗәләре һәм бер үк вакытта конкурсның гомуми нәтиҗәләре булып конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсенә кертелгән конкурс комиссиясе карары санала.

4.6. Министрлыкта конкурска нәтиҗәләр ясау һәм дәүләт гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасына кандидат турында карар кабул итүгә нигез булып кандидатларга бирелгән тавышлар саны, кандидатлар дәгъва кылган вазыйфа кергән структур бүлекчә җитәкчесе фикере санала.

4.7. Конкурс үткәрү нәтиҗәсендә конкурс игълан ителгән гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасы (гражданлык хезмәте вазыйфасына кадрлар резервы) буенча барлык тиешле таләпләргә җавап бирүче кандидатлар ачыкланмаганда, конкурс комиссиясе өстәмә конкурс сынаулары үткәрү турында карар кабул итүгә яки яңа конкурс үткәрү турында тәкъдим кертүгә хокуклы.

4.8. Дәүләт гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасына конкурс нәтиҗәләре буенча дәүләт гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасына конкурсның җиңүчесен билгеләү турында министр боерыгы кабул ителә, һәм аның белән хезмәт килешүе төзелә.

Конкурс комиссиясе шулай ук дәүләт гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасына конкурсның җиңүчесе булмаган, әмма һөнәри һәм шәхси сыйфатлары югары бәя алган кандидатны Министрлыкның кадрлар резервына кертү турында рекомендация характерындагы карар кабул итәргә хокуклы.

Кандидат ризалыгы белән аны гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасы кергән төркем буенча гражданлык хезмәте вазыйфасын биләү өчен кадрлар резервына кертү турында министр боерыга кабул ителә.
Конкурста җиңүчесе булган гражданлык хезмәткәрен (гражданны) кадрлар резервына кертү министр боерыгы белән рәсмиләштерә.

4.9. Конкурс нәтиҗәләре турында мәгълүмат ул тәмамланганнан соң 7 көн эчендә кандидатларга язма формада юллана, шул ук вакытта конкурста катнашу өчен документларны электрон юл белән тапшырган кандидатларга - электрон документ формасында дәүләт гражданлык хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасын кулланып, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән юлланыла.
Конкурс нәтиҗәләре турында мәгълүмат шул ук вакыт аралыгында Министрлыкның рәсми сайтында һәм "Интернет" челтәрендә урнаштырыла.

4.10. Кандидат конкурс комиссиясе карарын Россия Федерациясе канунлыятенә нигезләнеп шикаять белдерүгә хокуклы.

4.11. Конкурста катнашуга кертелмәгән кандидатларның һәм конкурста катнашкан кандидатларның документлары аларның язма гаризалары буенча конкурс тәмамланган соң өч көн эчендә кире кайтарылырга мөмкин. Әлеге вакыт узганчы документлар Министрлык архивында саклана, аннан соң юк ителергә тиеш.
Конкурста катнашу өчен электрон формада тапшырылган документлар өч ел дәвамында саклана, аннан соң юк ителергә тиеш.

4.12. Конкурста катнашу белән бәйле чыгымнар (конкурс урынына барып кайту, торак өчен түләү, яшәү, элемтә чараларыннан файдалану һ.б.) кандидатларның үз хисабыннан башкарыла.

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турында Нигезләмәгә
Кушымта

Татарстан Республикасы мәдәният министрына

________________________________________
(министр инициаллары, фамилиямсе)

________________________________________
(гариза бирүченең исем-фамилиясе, атысынынң исеме)

________________________________________
(гариза бирү вакытына яшәү адресы; эш урыны, вазыйфасы)

________________________________________
(кәрәзле телефон, эл. почта)

**Гариза**

Мине Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) түбәндәге дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфасын биләү өчен конкурста катнашуга кертүегезне сорыйм:

____________________________________________________________________________
(наименование должности и подразделения)

“Россия Федерациясенең дәүләти гражданлык хезмәте турында” 2004 елның 27 июле № 79-ФЗ Федераль законы, 2003 елның 16 гыйнвары №3-ТРЗ Татарстан Республикасы законы “Россия Федерациясе дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында” 2005 елның 1 феврале № 112 Россия Федерациясе Президенты Указы, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турында Нигезләмә, шул исәптән вакантлы вазыйфа таләп ителгән квалификация таләпләре белән таныштым. “Шәхси мәгълүматлар турындагы” 2006 елның 27 июле № 152-ФЗ Федераль законы таләпләре нигезендә шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә риза.

Конкурс үткәрү датасы һәм урыны турында мәгълүматны E-mail яисә күрсәтелгән кәрәзле телефон номерына СМС-хәбәр ярдәмендә җиткерүгә риза.

Гаризага беркетәм:

____________________________________________________________________________
(беркетелгән документларны санап чыгарга)

______________ ____________________ ______________________________
(дата) (имза) (имзаның чишелеше)